## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Сыйныф: 4 Б
Атнага: 1сәг
Барлыгы- 35 сәг.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга «Әдәби уку» предметын коммуникатив технология нигезендә укытуның үрнәк программасы (1 — 4 нче сыйныфлар)Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, 2017 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2017-2018 уку елына укыту планы (№__ педсовет протоколы, 2017 ел).

Дәреслек. . Күңелле татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмаларының 4 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен)Төзүчеләре:Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина Татар теле китабы. Ике кисәктән тора. Казан. «Татармультфильм» нәшрияты, 2014 ел.

**Әдәби укуга өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.**

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә башлангыч сыйныфларда әдәби укуны укытуныңнәтиҗәләре билгеләнде.

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр***

– үзе яшәгән туган җирнең һәм зур ватанның берлеге, бердәмлегенә карата хөрмәт хисләре туу;

– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караштa булу;

– әхлаклылык һәм гуманизм кебек гомумкешелек принципларын, гаилә һәм мәктәп кыйммәтләрен хөрмәт итү һәм аларны үтәүгә омтылу.

***Метапредмет нәтиҗәләр***

– уку максатын (сөйләм бурычын) аңлап, аңа тәңгәл килерлек мәгълүматны сайлый белү;

– гомуми уку күнекмәләренә ия булу һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу;
– үз эшчәнлегеңне планлаштыру, аны контрольдә тоту һәм бәяли белү;
– укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан мөстәкыйль файдалана алу;
– таблица, схема, кагыйдә формасында бирелгән белешмә материалдан файдалану;
– коммуникациягә керә белү сәләтләре булу;
– парларда, төркемнәрдә эшли белү күнекмәләре булу.

***Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча татар теленә өйрәтүнең***

***предмет нәтиҗәләре***

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча башлангыч мәктәпне тәмамлаучы түбәндәге күнекмәләргә ия була:

***Уку***

- татар сүзенең график образын аның авазлы образы белән чагыштыру;
- укуның орфоэпик һәм интонацион нормаларын белү;
- өйрәнелгән материалга нигезләнгән кечкенә күләмле текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле итеп һәм әйтелеш нормаларын саклап уку;
- тексттан кирәкле мәгълүматны табу;
- укылган мәгълүматка бәйле гади нәтиҗәләр ясау;
- контекст нигезендә таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсенә төшенү.

***Сөйләү***

- программа кысаларында сөйләм бурычына туры килгән лексик-грамматик материалны кулланып, әңгәмәдәшең белән контактка керү: сөйли, сорый белү; сөйләмне башлый, дәвам итә, төгәлли белү;
- телдән монологик сөйләм (тасвирлау, хикәяләү, фикер йөртү) күнекмәләренә ия булу; орфоэпик нормаларны үтәү;
- укыганның эчтәлеген сөйләү, эчтәлеккә карата фикереңне әйтә белү;
- текстны үзгәртеп, аналогик текстлар төзеп сөйләү;
- көндәлек аралашу ситуацияләренә бәйле сөйләм этикеты үрнәкләрен гамәли үзләштерү (сәламләү, саубуллашу, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, үтенеч белдерү);
- сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, гади диалогларда катнашу;
- предметны, персонажны яки рәсемне тасвирлау.

***Тыңлап аңлау***

- аралашу барышында укытучының һәм сыйныфташларның сөйләмен ишетеп аңлау, вербаль яки вербаль булмаган рәвештә җавап кайтару;
- тыңлана торган тексттагы мәгълүматны аңлау, аның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.

***Язу***

текстан сүзләрне, сүзтезмәләрне, гади җөмләләрне күчереп язу;

- үрнәк буенча бәйрәмгә чакыру язу;
- үрнәк буенча дустыңа хат язу;
- сөйләм бурычын аңлап, кыскача үз фикереңне язмача белдерү.
- текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;
- терәк сүзләр ярдәмендә кечкенә хикәя төзеп язу;

**II.Укыту предметының эчтәлеге**

| Тема | Тема буенча билгеләнгән тематик эчтәлек |
|---|---|

| | |
|---|---|
| **Яңаукуелыбашлана** | С. Маршак. “Һәратнадаҗидекөн”.<br>Х.Гарданов. «К»ныдөресәйтегез”.<br>Р.Миңнуллин. “Үсми калган хәреф”.<br>Б.Рәхмәт. «Эшурыны».<br>Г. Тукай. “Эшбеткәчуйнарга ярый”. |
| **Туган як табигате** | Г. Тукай.“Елның 4 фасылы”.<br>Г. Гәрәева. “Көзһәмбалаларҗыры”.<br>Җ. Тәрҗемановның “Табигать китабы”.<br>Г.Лотфи. “ПеснәкбеләнӘнисә”. |
| **Хайваннардөньясында** | Ә.Кари. “Тиен”. |
| **Кышкыуеннар** | Г. Бакир. “Кышкыуеннар”.<br>А. Алиш.“Куянкызы”. |
| **Минем дусларым** | Г. Бәширов. “Сылтау”.<br>И. Туктар. “Алма”. |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз** | Р.Мингалим.“Дөньяда бер эт бар иде”.<br>Г. Тукайның “Кызыклы шәкерт”.<br>Г.Мөхәммәтшин.“Ак песи”.<br>Р. Батулла. “Чикыл белән Мырый”. |
| **Язгыбәйрәмнәр** | “Каргаботкасы” тексты.<br>“Әби белән онык” тексты.<br>В. Осеева. “Дүрт кыз”. |
| **Минем туганилем** | “Татарстан – минем республикам” , “Казан – Татарстанныңбашкаласы” текстлары |
| **Чәчәклеҗәй, ямьлеҗәй** | “Исәнме, җәй!” темасына сөйләшү.<br>Ш. Галиев. “Җәйге болында”. |

**III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.**

| № | Өйрәнелә торган бүлек, | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|

| | **уку материалының темасы** | | **Планлаштырылган** | **Факт буенча** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Яңа уку елы башлана. | Китаптагы текст белән танышу, уку, тәрҗемә итү. Эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү | 7.09 | |
| 2. | Р.Миңнуллин. “Үсми калган хәреф”. | Эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү | 14.09 | |
| 3. | Х.Гардановның «К” хәрефен белегез, “К”ны дөрес әйтегез” шигыре. | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау | 19.09 | |
| 4. | Б.Рәхмәтнең «Эш урыны» хикәясе | Шигырьне уку, сорау-биремнәргә җавап эзләү. | 26.09 | |
| 5. | Б.Рәхмәтнең «Эш урыны» хикәясе | Хикәяне укып чыгу һәм тирән сораулар буенча анализлау | 3.10 | |
| 6. | Г. Тукай. “Эш беткәч уйнарга ярый”. | Әкиятне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау | 10.10 | |
| 7. | Яңа уку елы башлана. Темасын кабатлау. | Хикәяне укып чыгу һәм тирән сораулар буенча анализлау | 17.10 | |
| 8. | Туган як табигате. | Китаптагы текст белән танышу, уку, тәрҗемә итү. | 24.10 | |
| 9 | Г.Лотфиның “Песнәк белән Әнисә” хикәясе. | Китаптагы текст белән танышу, уку, тәрҗемә итү. Эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү | 17.11 | |
| 10 | Ә.Кариның “Тиен” шигыре. | Эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү | 14.11 | |
| 11 | Г.Тукай “Ташбака белән Куян” мәсәле | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп | 21.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | фикерне табу, нәтиҗә ясау | | |
| 12 | “Яшел энәле керпе” әкияте. | Шигырьне уку, сорау-биремнәргә җавап эзләү. | 5.12 | |
| 13 | Г. Бакирның “Кышкы уеннар” хикәясе | Хикәяне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау | 12.12 | |
| 14 | А. Алишның “Куян кызы” әкияте | Әкиятне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау | 19.12 | |
| 15 | Г. Бәшировның “Сылтау” хикәясе | Хикәяне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау | 9.01 | |
| 16 | **Дүрт аяклы дусларыбыз**. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, белемнәрне тикшерү | 16.01 | |
| 17 | Р.Мингалим “Дөньяда бер эт бар иде” | Әңгәмә, сәнгатьле уку | 23.01 | |
| 18 | Г.Тукай “Кызыклы шәкерт” | Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү | 30.01 | |
| 19 | Г.Мөхәммәтшин “Ак песи” | Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | 6.02 | |
| 20 | **Язгы бәйрәмнәр.** “Карга боткасы” тексты. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, белемнәрне тикшерү | 13.02 | |
| 21 | Л. Толстой “Әбисе белән оныгы” | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау. | 20.02 | |
| 21 | М.Газизов “Рәхмәт”. | Сәнгатьле уку, тәрҗемә итү, сораулар төзү | 27.02 | |
| 22 | В. Осеева “Дүрт кыз” | Әңгәмә, сөйләү, образларга бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү | 6.03 | |
| 23 | **Минем туган илем.** Алексеевск – минем туган төбәгем. | Әңгәмә, сөйлә | 13.03 | |
| 24 | З.Туфайлова “Туган ил”. | Әңгәмә, сөйләү, образларга бәяләмә, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү. | 20.03 | |
| 25 | “Татарстан – минем республикам” | Әңгәмә, тәрҗемә эше, сөйләү | 3.04 | |
| 26 | “Казан – Татарстанның башкаласы” текстлары | Яңа материал белән танышу, укытучының кереш сүзе, укылган текст буенча фикер алышу. | 10.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 27 | **Чәчәкле җәй, ямьле җәй.** | Әңгәмә, сөйләү, сүзлек эше, | 17.04 | |
| 28 | Шәүкәт Галиев “Җәйге болында” | Әңгәмә, сөйләү, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү | 24.04 | |
| 29 | Чәчәкле җәй, ямьле җәй. | Әңгәмә, сөйләү, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү | 1.05 | |
| 30 | “Җәйге болында” | Әңгәмә, сөйләү, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү | 8.05 | |
| 31 | Татар халык әкияте “Шүрәле” | Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү | 27.04 | |
| 32 | Татар халык әкияте “Шүрәле” | Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү | 4.05 | |
| 33 | Гомумиләштереп кабатлау.. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, белемнәрне тикшерү | 15.05 | |
| 34 | Ел буена үткәннәрне каббатлау.. | Кабатлау | 22.05 | |
| 35 | Йомгаклау дәресе. | Кабатлау | 29.05 | |